РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Малосалтыковского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Кече Салтык**
**авыл җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Б. Урманче, 9 с. Малые Салтыки, 422812
тел. (8277)36-2-18, факс: (8277) 36-2-18
ОКПО 9405059 ОГРН 1061672018033
ИНН/КПП 1622004757/1162201001

Б.Урманче урамы, 9,Кече Салтык авылы, 422812,
тел. (8277)36-2-18, факс: (8277) 36-2-18
ОКПО 9405059 ОГРН 1061672018033
ИНН/КПП 1622004757/1162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**«03» сентября 2018г.** **№ 6**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 22 маендагы “Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 4 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 22 маендагы 4 санлы карары белән расланган Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5 бүлекнең 5.12 пунктындагы 1-3 абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.12. Шикаять карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шулай ук кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт курсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларга кертелгән опечаткаларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан республикасы норматив-

хокукый актлары, муниципаль норматив-хокукый актлар белән каралмаган түләүләрне кире кайтару формаларында;

2) шикаять канәгатьләндерелми.”.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендлар аша халыкка белдерергә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Кече Салтык авылы, Бакый Урманчы ур., 9, Мәдәният йорты бинасы,

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Кече Мәрәтхуҗа авылы, Вахитов ур., 9, авыл китапханәсе, шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Кече Салтык авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Г. Җиһаншин